ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.10.2022 с.Старое Дрожжаное №510

2023 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.Р. Измайловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның "05" октябрь 510 номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 105678 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 159325 |

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова